
Сергей Михалков

УЛЫМ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ



Сергей Михалков

УЛЫМ БЕЛӘН СӨЙЛӘШҮ



ТАТКНИГОИЗДАТ
Яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе
Казан 1957

* * *

Тәржемәчесе
Ә. Давыдов

Редакторы
Салих Хәким

Тышлык художнигы
Э. Дьячкова

Художник
В. Высоцкий
рәсемнәреннән күчермә

* * *

КЕЧЕ ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН



Улым, тыңла, сиңа сөйлим мин
Үткәннәрен туган иленнен,

Азатлыкка килгән юлларын,
Көрәшләрдә янган улларын.

Ничек алар данлы бер елны,
Бөтен Мәскәү, бөтен Питерны

Туплап кызыл байрак астына,
Ирек яулап хезмәт халкына,

Көрәшкәннәр, ничек җиңгәннәр,
Сиңа бәхет алып биргәннәр!

Син мәктәпкә өченче ел
Йөрисең шатланып, көлеп.

Бездә һәммә бала укый,
Бар да галим синең кебек.

Ә моннан күп еллар элек
Патша булган илнең башы,
Булмаган күп балаларның
Дәфтәре һәм әлифбасы.

Тик байларның, купецларның
Уллары йөргән мәктәпкә,
Эшче-крестьян балалары
Мәктәпкә бик аз эләккән.





Мужик ел саен җир сөргән,
Чәчкән ул, тарттырган онын,
Ә икмәге байга кергән,
Бизәп торган бай табынын.

Хәлдән тайганчы тырышкан,
Үзе һаман да ач яткан,
Ә бай үзенең этләрен дә
Алдан калганчы ашаткан.

Йөз чакрымга урман, кырлар,
Яшел болын тирә-ягың,
Тик алпавытныкы алар,
Кая бассаң да аягың.

Болында печән — байныкы,
Урманда утын — аныкы,
Якын барма — төрмә!

Ә бай баеп яши бирә,
Тәмле генә ашый бирә,
Кәеф-сафа сөрә.

Ә шәһәрдә, еллар буе
Рәхимсез язмышын тиргәп,
Эшче, гүргә кергәнгәчә,
Фабрикант өчен тир түгә.

Эшлә станок янында,
Утлы домна ялкынында,
Верстагында да эшлә,
Ләкин байга каршы дәшмә!

Әгәр инде. түзә алмасаң,
Йодрыгыңны йомарласаң,
Кулга кызыл байрак алсаң,
Үз хакыңны сорап барсаң, —






Жандармнар тотып ала,
Кулларына богау сала,
Каторжаннар җырын җырлап,
Атлыйсың Себергә таба.

Ләкин ярлы турында да
Уйлаучылар җирдә булган.
Омтылган алар халыкны
Җитәкләргә туры юлдан.

Булсын, дигәннәр, халыкның
Тамагы тук, өсте бөтен.
Байлар кулы астында ул
Интегеп түкмәсен көчен.

Күрше илләр арасында,
Куәт, ямьдә канатланып,
Торсын эшче-крестьяннарның
Беренче азат ватаны.



Төрмәләргә ташлаганнар,
Богау кулны кырган бик нык,
Ләкин беркем, — патша, алла, —
Җиңә алмаган большевикны!

Һәм моннан кырык ел элек
Азатлык сәгате суккан:
Петроград коралланган,
Эшче сыйныф яуга чыккан.


Кем сыналган көрәшләрдә
Хаклык өчен изге юлда,
Халыкны шул җитәкләгән
Унҗиденче данлы елда.

Башкаларның хыялында
Әле теләк булып яткан
Бөтен уйлар, бөтен нәрсә
Безнең илдә эшкә ашкан,
Һәм боларның син һәммәсен
Үз күзең белән күрәсең.

Кара син туган иленә,
Бар да бит безгә бирелгән:
Тау, болыннар, тирә-ягың...
Йөз чакрымга урман, кырлар,
Бар да халыкныкы алар, —
Кая бассаң да аягың!

Зур бакчалар байга түгел,
Безгә җимеш бирә,
Сарайларда граф түгел,
Укучылар тора.

Байларга без ташымыйбыз
Капчыклап бодай бөртеген,
Бөек Днепрогэска да бит
Бай я купец хуҗа түгел.



Кырларда иген игәбез,
Тимер, күмер чыгарабыз,
Газ кертәбез өйгә.
Күмере дә, арышы да,
Газы, йорты — барысы да,
Барысы да безгә!

Завод-фабриклар чыгарган,
Бөек Ватан горурланган
Бар нәрсә безнеке!
Дошманнарның котын алып
Торган иксез-чиксез байлык
Мәңгегә безнеке!



Күр син, Кремль капкасыннан
Чыгып, Кызыл мәйдан аша
Әкрен генә үтеп бара
Безгә күптән таныш апа.

Профессор, депутат ул,
Орел каласы халкыннан,
Кырык ел элек Орелда ул
Байларда кухарка булган.

Күр син генерал узганын!
Ә күп еллар моннан
Баррикададан кайтып ул
Смольныйда сакта торган.

Бик яшь булса да ул чакта,
Күпме авырлык күтәргән:
Революция кушканны
Ул намус белән үтәгән.



Күрче, укучылар бара,
Шатлык белән җирне күзләп,
Берсе латыш, берсе якут,
Берсе, күрәсеңме, үзбәк.

Алар тигез, алар тату,
Бер отрядка нык берләшкән,
Ә сугышта әтиләре
Янәшә басып көрәшкән.


Күпме авырлык кичердек,
Давыл аша юллар ярдык,
Ләкин көрәшә-көрәшә
Үстек, һәр көн алга бардык.

Совет кешесе далаларда
Искиткеч шәһәрләр корды,

Шаулап аккан елгаларның
Агышын кирәк якка борды.

Могҗизалар тудырды ул,
Хезмәткә бар көчен бирде,
Фәнне күпме өйрәнде ул,
Күпме яңа серләр белде!

Бөек изге эш өчен дип
Рудалардан металл алды,
Үз хезмәтен, туган йортын
Яклады һәм яклап калды.






Изге хакыйкать өчен ул
Үтте күпме көрәш юлын,
Аналар озатып калды:
„Батыр бул, дип, газиз улым!“

Батыр совет генералы,
Куркусыз совет солдаты
Көрәшеп ала алмаган
Бер крепость та калмады.

Укы, яшә, улым, җаным,
Шатлан — син совет гражданы,
Сайла тормышта дөрес юл,



Көрәшләрдә һәм хезмәттә,
Шатлыкларда һәм михнәттә
Ватаныңа син тугры бул.

Һич онытма ләкин шуны:
Син тудың азат Ватанда,
Ленин байрагы астында,
Кызыл йолдыз яктысында.

Җитәкли Партия безне,
Ә халык һәм Партия бер,
Шуңа күрә совет халкы
Мәңге җиңелмәс баһадир.

Без һаман алга карыйбыз,
Якты максатны күрәбез,
Һәм үзебез теләгән тормышны
Без туган илдә төзәрбез!



Сергей Михалков

РАЗГОВОР С СЫНОМ

(на татарском языке)

Художество редакторы *Г. Ш. Ахметзянов*

Техник редакторы *Г. Н. Неделько*

Корректоры *М. М. Мирсалихова*

Наборга бирелде 23|VIII-1957 ел. Басарга кул куелды 25|X-1957 ел.
Кәгазь форматы 84×108¹|₃₂. Учет.-изд. таб. 0,56. Басма табак 1,0 (0,82).
Табакта 44000 хәреф. Заказ № 0332. Тираж 10.000. Бәясе 20 тиен.

ТАССР Культура министрлыгының Татполиграф типографиясе.
Казан, Миславский ур., йорт № 9.

Бәясе 20 тиен

ТАТКНИГОИЗДАТ · 1957